| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 28 апреле №16

"Ивановка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 7 номерлы карары белән расланган Ивановка авыл җирлеге җирле җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, әгъзасына, үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралар куллану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. "Ивановка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 7 номерлы карары белән расланган Ивановка авыл җирлеге җирле җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, әгъзасына, үзидарәсенеңсайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралар куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен) сүзләренә алмаштырырга (алга таба - Татарстан Республикасы Рәисе)»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 1, 3 абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. "Ивановка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның

26 мартындагы 7 номерлы карары белән расланган "Ивановка авыл җирлеге җирле җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, әгъзасына, үзидарәсенеңсайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралар куллану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 14 мартындагы 4 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5 нче йорт, Аккүл авылы, Колхоз урамы, 16Б йорт, Медведка авылы, Юл урамы, 32 нче йорт, Михайловка авылы, Үзәк урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.П. Бодряева